**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Контрольно-счетная палата**
**Рыбно-Слободского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Контроль-хисап палатасы**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.01.2016 № 3

Балык Бистәсе штп.

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны тормышка ашыру чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның $43^{1}$ маддәсе, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмә нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Контроль-хисап палатасының (алга таба – Палата) норматив характердагы (норматив характердагы нигезләмәләр кертелгән) күрсәтмәләрен (боерыкларын) чыгарганда, күрсәтелгән муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында мәгълүматларны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен юнәлтү буенча Палата эше (алга таба – регистр) законнарда билгеләнгән тәртиптә, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2016 елның 29 гыйнварындагы 12пг номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында мәгълүматлар җыю һәм җибәрү буенча үзара эшчәнлек регламенты белән гамәлгә ашырыла.

2. Палатаның муниципаль норматив хокукый актларын һәм алар турында мәгълүматларны регистрга кертү өчен җибәрүгә җаваплы зат итеп палата белгечен билгеләргә.

3. Әлеге боерыкның 2 пунктында каралган вәкаләтләрнең, палата белгече вакытлыча булмаган очракта, Палата рәисенә йөкләнүен тәгаенләргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Рәис А.И.Бәдретдинов